КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 ноябрь г.Казань № 1035

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 21 июнь, 484 нче карары белән расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 484 нче белән расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

табигый газ (метан) – мотор ягулыгы сыйфатында кулланыла торган кысылган яки сыекландырылган табигый газ;

тәкъдим (заявка) – сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан әлеге Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелеп тапшырыла торган документлар;

вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла торган транспорт чараларын яңадан җиһазландыру чараларын һәм Федераль кагыйдәләрне тормышка ашыру өчен җаваплы, шулай ук Россия Федерациясе Энергетика министрлыгы белән үзара мөнәсәбәтләр өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы. Вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы билгеләнә;

вәкаләтле оешма – вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән тәкъдимнең (заявканың) әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерүне башкаручы оешма. Вәкаләтле оешма итеп «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәле кулланыла торган технологияләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе билгеләнә;

сервис – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасын булдыру турында» 2020 ел, 2 ноябрь, 986 нчы карары нигезендә эшләнгән һәм электрон хисаплау машиналары өчен программалар, мәгълүматлар базасы (базалары) һәм интеллектуаль эшчәнлекнең башка нәтиҗәләре рәвешендә булган, дәүләт ярдәме күрсәтү чараларыннан электрон рәвештә файдалану максаты белән сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәр (заявкалар) бирүгә хокукларын тормышка ашыру өчен билгеләнгән мәгълүмат системасы. Сайлап алуда катнашучыларның сервис функциясеннән файдалану мөмкинлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге https://subsidiya.tatar.ru/ яки https://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча урнашкан сайт аша йә сервиста басылып чыккан сервистан файдалану турындагы килешү нигезендә мобиль кушымта аша гамәлгә ашырыла;

транспорт чаралары – автомобиль техникасының барлык төрләре (җиңел автомобильләр, җиңел йөк транспорты, йөк автомобильләре, автобуслар, коммуналь техника, махсус билгеләнештәге автомобиль техникасын кертеп). Шул ук вакытта транспорт чаралары Россия Федерациясе территориясендә әйләнешкә чыгарылырга һәм теркәлергә тиеш, 2021 елда чыгарылыш елы – 2013 елдан да иртәрәк, 2022 елда һәм аннан соңгы елларда агымдагы финанс елына кадәрге биш елдан да иртәрәк булмаска тиеш;

транспорт чараларын яңадан җиһазландыру – транспорт чараларына сертификацияләнгән, газ баллоны җайланмасын урнаштыру һәм аны көйләү эшләрен башкару; нәтиҗәдә транспорт чараларының мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) куллану мөмкинлеге барлыкка килә;

транспорт чаралары хуҗасы – транспорт чаралары милекчесе, шулай ук хуҗалык алып бару хокукында яки оператив идарә хокукында йә башка законлы нигездә (аренда хокукы, тиешле органның әлеге затка транспорт чараларын тапшыру турындагы боерыгы һәм башка шундыйлар) транспорт чараларына ия булган зат.

Үзенең эш урынындагы яки хезмәт бурычларын башкару йөзеннән транспорт чаралары белән идарә итүче зат транспорт чараларының хуҗасы булып тормый;

сынау лабораториясе – транспорт чаралары конструкциясенә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, транспорт чараларының тиешле категорияләренең техник регламенты таләпләренә туры килүне бәяләү эшләрен үткәрүгә аккредитацияләнгән, продукцияне әйләнешкә чыгарганнан соң, техник торышны бәяләү (техник тикшерү) яки тикшерү формасында аның техник регламент таләпләренә туры килүен бәяләү эшен гамәлгә ашыручы һәм Евразия икътисади комиссиясе Советының 2018 елның 5 декабрендәге 100 номерлы карары белән расланган Аккредитацияләнгән органнарны (шул исәптән сертификацияләү органнарын, сынау лабораторияләрен (үзәкләрен)) туры килүләре бәяләнгән билге буенча Евразия икътисади берлегенең туры килүләре бәяләнгән билге буенча органнарның бердәм реестрына кертү, аны формалаштыру һәм алып бару тәртибе нигезендә Евразия икътисади берлегенең туры килүләре бәяләнгән билге буенча органнарның бердәм реестрына кертелгән оешма;

сайлап алуда катнашучылар – вәкаләтле органга тәкъдим (заявка) керткән, яңадан җиһазландыру һәм техник хезмәт күрсәтү пунктлары булган, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып барган һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли торган, шартнамә нигезендә мөстәкыйль яки өченче затларны җәлеп итеп, транспорт чараларын мотор ягулыгы буларак табигый газны (метанны) куллануга яңадан җиһазландыру һәм аларга техник хезмәт күрсәтү хокукларын һәм бурычларын үз өстенә алган, яңадан җиһазландыру һәм техник хезмәт күрсәтү пунктларын тикшерү буенча ведомствоара комиссиянең Федераль кагыйдәләр таләпләренә туры килү-килмәүгә вәкаләтле орган боерыгы белән расланган, түбәндәгеләрнең булуын раслый торган уңай карары булган юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр:

«Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм (яки) газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча стимул бирү характерындагы программаларны тормышка ашыруда катнашучы, табигый газ (метан) сатуны гамәлгә ашыручы башка оешма белән төзелгән партнерлык килешүе (алга таба – партнерлык килешүе);

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сынау лабораторияләре белән хезмәттәшлек турында шартнамәләр;

Идел буе федераль округы территориясендә урнашкан баллоннарны яңадан тикшерү пунктлары белән хезмәттәшлек турында шартнамә;

башкарылган эшләргә кертелгән үзгәрешләрне һәм аларның актларын исәпкә алып, башкарылган эшләрне транспорт чаралары паспортының яки транспорт чараларын теркәү турындагы таныклыкның күчермәләре белән раслап, 2019 елның 1 гыйнварыннан кимендә 10 берәмлек күләмендә транспорт чараларын яңадан җиһазландыру тәҗрибәсен раслый торган документлар;

яңадан җиһазландыру өчен кимендә ике пост һәм, йөк транспорт чараларын һәм автобусларны яңадан җиһазландыруны гамәлгә ашырган очракта, мондый транспорт чараларын яңадан җиһазландыру өчен кимендә бер махсус пост;

кимендә өч җиңел транспорт чарасы һәм клиентлар зонасы өчен кимендә 10 кв.метр мәйданлы туплау мәйданчыгы;

төп җитештерү мәйданчыгында газ җиһазының, шул исәптән газ балоннары һәм капот асты җиһазының даими тулыландырылып тора торган кимендә 10 комплект склад запаслары;

кысылган табигый газ белән эшләү өчен автомобильләрне яңадан җиһазландыру эшләрен үткәрүгә гамәлдә булган ярашканлык сертификаты;

субсидия алучы – сайлап алу критерийларына, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү һәм тәкъдимнәр (заявкалар) керү чираты нигезендә сайлап алуда җиңүче дип танылган сайлап алуда катнашучы;

субсидия бирү турында килешү – вәкаләтле орган һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгән субсидия алучы арасында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү;

гарантия срогы – башкарылган эшләр өчен транспорт чаралары хуҗасы тарафыннан яңадан җиһазландырылган транспорт чараларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен үтәү шарты белән газ баллоны җиһазының эшләвенә транспорт чараларын яңадан җиһазландыру эшен башкарган яңадан җиһазландыру һәм техник хезмәт күрсәтү пункты җавап бирә торган 1 ел яки 30 000 км (кайсысы алдан булуга карап) тәшкил иткән минималь гарантия срогы;

яңадан җиһазландыру турында шартнамә – транспорт чаралары хуҗасының яңадан җиһазландыру һәм техник хезмәт күрсәтү пункты белән транспорт чараларын яңадан җиһазландыру эшләрен үткәрүгә төзелгән, түбәндәге нигезләмәрне үз эченә алган шартнамә:

а) башкарыла торган эшләргә кимендә 1 ел яки 30 000 км (кайсысы алдан булуга карап) тәшкил иткән минималь гарантия срогына карата таләпләр һәм гарантия шартлары турында;

б) транспорт чаралары хуҗасын яңадан җиһазландырылган транспорт чараларын эксплуатацияләү кагыйдәләре белән таныштыру һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыруны гамәлгә ашырган затның транспорт чаралары хуҗасына мондый транспорт чараларын эксплуатацияләү һәм аңа хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре турында инструктаж үткәрүе турында;

в) транспорт чаралары хуҗасын яңадан җиһазландырылган транспорт чараларының иминлеген Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән махсуслаштырылган лабораториядә тикшерү, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә транспорт чаралары конструкциясенә кертелгән үзгәрешләрне теркәүгә алуны гамәлгә ашыру бурычлары белән таныштыру;

г) транспорт чаралары хуҗасының вәкаләтле орган, Татарстан Республикасының күзәтчелек органнары тарафыннан газ баллоны җайланмасын урнаштыру таләпләре үтәлешенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы турында;

д) табигый газ белән эшләү өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләп чыгарылган, элек кулланышта булмаган яңа двигатель кую (транспорт чараларының моторын алыштыру) турында (кирәк булганда);

е) бирелгән ташламаның фактта гы күләме турында.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.»;

8 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз илебездә җитештерелгән, урнаштырылган газ баллоны: I тип баллон өчен – 2023 елдан башлап, II тип баллон өчен – 2024 елдан башлап, III тип баллон өчен – 2020 елдан башлап;»;

10 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар тәкъдимне (заявканы), сервистан файдаланып, электрон төрдә дә, кәгазь чыганакта да бирергә хокуклы. Тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә бирү сервисның рәсми сайтында http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru яисә сервисның мобиль кушымтасында гамәлгә ашырыла. Сайлап алуда катнашучы gosuslugi.ru (РФ Дәүләт хезмәтләре) рәсми сайтында Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (БИАС) расланган исәпкә алу язмасыннан файдаланып, шәхси кабинетын авторизацияли. Документларны электрон төрдә биргәндә субсидия бирү турындагы гариза сервиста формалаштырыла, ә субсидия бирү турындагы гаризага теркәлә торган документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан сервиска аларның сканерланган күчермәләре рәвешендә күчереп кертү юлы белән бирелергә тиеш. Тәкъдимне (заявканы), сервистан файдаланып, электрон төрдә биргәндә, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы вәкаләтле органга түбәндәге документларны үз эченә алган тәкъдим (заявка) бирә:»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«газ баллоны җиһазын сатуны һәм (яки) аны транспорт чараларына урнаштыруны күздә тота торган транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турындагы шартнамәнең барлык өстәмә килешүләре белән (әлеге Тәртип белән расланган мондый шартнамәгә карата таләпләр нигезендә) күчермәсен;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сервистан файдаланып, электрон төрдә бирелгән очракта, тәкъдимгә (заявкага), сайлауда катнашучы тарафыннан гади электрон имза (алга таба – гади электрон имза) куела, гади электрон имза дигәндә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кодлар, парольләр яки башка чаралар ярдәмендә билгеле бер зат тарафыннан электрон имза формалаштыру фактын раслый торган электрон имза аңлашыла. Тәкъдим (заявка) биргәндә гади электрон имзаны куллану тәртибе вәкаләтле орган тарафыннан сервиста урнаштырылган, оферта шартларын кабул итү юлы белән төзелә торган гади электрон имза куллану турындагы килешүдә билгеләнә. Тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә биргәндә гади электрон имзадан файдалану турындагы килешү формасы вәкаләтле орган тарафыннан раслана һәм сервиста урнаштырыла.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Тәкъдимне (заявканы) кәгазьдә биргәндә тапшырыла торган документлар басма хәрефләр белән аерырлык итеп язылган һәм һәр пункты тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Чистартулар һәм төзәтүләр (сайлап алуда катнашучының мөһере белән (мөһере булганда) яки сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми. Тәкъдимнең (заявканың) барлык битләре номерлап чыгылырга тиеш. Документларның күчермәсе сайлап алуда катнашучының мөһере белән (мөһере булганда) расланырга һәм шуңа вәкаләте булган затның имзасы белән яки сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланырга тиеш. Тәкъдим (заявка) тегелгән һәм тәкъдимнең (заявканың) кире ягына, битләрнең гомуми санын күрсәтеп, сайлап алуда катнашучының мөһере белән (мөһере булганда) расланган һәм шуңа вәкаләте булган затның имзасы белән яки сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган булырга тиеш.

Тәкъдимне (заявканы) әзерләү буенча барлык чыгымнарны сайлап алуда катнашучы күтәрә.

Тәкъдимне (заявканы) кәгазьдә тапшырганда сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы вәкаләтле органга түбәндәге документларны үз эченә алган тәкъдим (заявка) тапшыра:

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү турында гариза;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча гарантия хаты;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтада бирелгән форма буенча әлеге Тәртипнең таләпләре нигезендә үткәрелгән эшләр турында гарантия хаты;

транспорт чаралары хуҗасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәхси мәгълүматларын бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгының күчермәсен теркәп, Россия Федерациясе гражданы – транспорт чаралары хуҗасы паспортының (Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә) күчермәсе;

транспорт чараларын теркәү турындагы таныклыкның күчермәсе;

газ баллоны җиһазын сатуны һәм (яки) аны транспорт чараларына урнаштыруны күздә тота торган транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турындагы шартнамәнең барлык өстәмә килешүләре белән (әлеге Тәртип белән расланган мондый шартнамәгә таләпләр нигезендә) күчермәсе;

башкарылган эшләр актының һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турындагы шартнамә буенча түләү турындагы документның күчермәсе. Шул ук вакытта физик зат белән төзелгән транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турындагы шартнамәдә түләүләрне кичектереп түләү каралган булса, әлеге кучектереп түләүне раслый торган документ тапшырыла;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турында хисап;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан транспорт чаралары конструкциясенә үзгәрешләр кертүгә бирелгән рөхсәт кәгазенең күчермәсе;

лизинг бирүченең транспорт чаралары конструкциясенә үзгәреш кертүгә ризалыгы (әгәр транспорт чаралары хуҗасы лизинг бирүче булса);

транспорт чараларын арендалау шартнамәсенең күчермәсе һәм транспорт чаралары хуҗасының транспорт чаралары конструкциясенә (әгәр аренда шартнамәсе төзелгән булса) үзгәреш кертүгә ризалыгы;

урнаштырылган газ баллоны паспортының һәм урнаштырылган газ баллоны җиһазына сертификатның күчермәсе;

двигатель паспортының күчермәсе яки двигательне сатып алу-сату шартнамәсенең күчермәсе (транспорт чаралары моторын алыштырган очракта);

кулланылган газ балоны җиһазына спецификациянең күчермәсе һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыру буенча башкарылган эшләрнең кыйммәтен һәм әлеге эшләргә бирелгән ташламаның исәп-хисабын күрсәтеп, транспорт чараларын яңадан җиһазландыру буенча башкарылган эшләр исемлеге;

урнаштырылган җиһазга сертификат номерын һәм баллон номерын күрсәтеп, двигательне газсыман ягулык белән тәэмин итү өчен транспорт чараларына җиһаз урнаштыру эшләрен башкаручы декларациясенең күчермәсе;

сайлап алуда катнашучы һәм транспорт чаралары хуҗасы арасында төзелгән ниятләр турындагы килешүнең күчермәсе (сайлап алуда катнашучы тарафыннан транспорт чаралары хуҗасы һәм «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән яки табигый газ (метан) сатуны гамәлгә ашыручы башка оешма белән өчьяклы килешү төзелгән очракта);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан, транспорт чараларының идентификация номерын, транспорт чаралары маркасын, транспорт чаралары хуҗасының фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булганда) яки атамасын, аның элемтәгә керү өчен телефон номерын һәм факттагы яшәү урынын яки урнашу урынын күрсәтеп, транспорт чаралары хуҗасына һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыру эшләрен башкару өчен фактта ташлама бирүне һәм аның күләмен документаль раслау (башкарылган эшләр акты, счет-фактура, чек һәм башкалар);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан транспорт чараларын газ ягулыгына яңадан җиһазландыру эшләрен үткәрү турындагы Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хәбәрнамәсен раслый торган документның күчермәсе;

салым органының тәкъдим (заявка) биргән айга кадәрге айның 1е хәленә карата бирелгән салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмауны раслый торган белешмә кәгазенең күчермәсе;

сайлап алуда катнашучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмавы турындагы белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучы юридик затның үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка, башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәве, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмавы турында сайлап алуда катнашучының белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 процenttан артмаган

Россия юридик заты булып тормавы турында сайлап алуда катнашучының белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавы турында сайлап алуда катнашучының белешмә кәгазе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (заявка), тиешле сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) язма ризалык.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә (әгәр юридик зат – транспорт чаралары хуҗасы кече яки урта эшмәкәрлек субъекты булса).

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә бирелмәсә (әгәр юридик зат – транспорт чаралары хуҗасы кече яки урта эшмәкәрлек субъекты булса), вәкаләтле орган әлеге мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән яки ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә ала.

Салым органының тәкъдим (заявка) биргән айга кадәрге айның 1е хәленә карата бирелгән салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмауны раслый торган белешмә кәгазенең күчермәсе сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелмәгән очракта, вәкаләтле орган әлеге мәгълүматларны ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә ала.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка, керү вакытын күрсәтеп, чират тәртибендә кергән көндә теркәүгә алына.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Тәкъдимнәрне (заявкаларны) карап тикшерү стадиясендә сайлап алуда катнашучының тәкъдимен (заявкасын) алмау өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 һәм 8 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән сайлап алу критериенә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән тәкъдимнең (заявканың) сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә һәм әлеге Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында тәкъдимнәргә (заявкаларга) карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучының тәкъдимнәр (заявкалар) бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң тәкъдим (заявка) бирүе;

вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

Карап тикшерү стадиясендә тәкъдимне (заявканы) алмау турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган сайлап алуда катнашучыга әлеге карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә тәкъдимне (заявканы) алмау турында хәбәрнамә җибәрә. Сайлап алуда катнашучы үзе тапшырган документ-

ларны кире алырга һәм әлеге Тәртипнең 10 һәм 11 пунктлары нигезендә яңадан тәкъдим (заявка) бирергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин